РЕШЕНИЕ КАРАР

№1 09 ноябрь 2023 ел

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Умәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 28 октябрендә 09.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 47 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 40 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 40 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде; җыенда катнашкан 0 кеше «тыелды».

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Умәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләре гамәлдә.

2. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Умәк торак пункты чикләрендә 18 яшькә җиткән гражданнардан 1000 сум күләмендә, гомуми авыру инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта махсус (урта һөнәри) уку йортларының көндезге бүлекләре студентларыннан тыш, түләүләр күләме 500 сум тәшкил иткән гражданнардан, үзара салым кертү белән килешеп:

- Умәк торак пунктында сүүткәргеч ремонтлау;

- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга стенд җиткерү» мәсьәләсе буенча карар кабул итәргә.

3. Җыен нәтиҗәләрен «Новая Кама» газетасында, Олы Шүрнәк авыл җирлегенең рәсми сайтында (Олы Шүрнәк, Алабуга.рф), мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

Олы Шүрнәк

авыл җирлеге башлыгы Н. И. Мельников